

Мордовиянен беренче студент отрядлары барлыкка килvенә – 50 ел, ә Россиядә беренче студент отрядлары 57 ел элек барлыкка килгән.
Россия Федерациясендә бу отрядларнын кабаттан янартылуына инде 12 елдан артык вакыт узып киткән. Бvген ботен илебез буенча әлеге хәрәкәттә – 200 меннән артык кеше. Әйтергә кирәк, бу оешма Россиядә ин масштаблылардан санала.     Мордовия пресс-vзәгендә торле буын стройотряд вәкилләре белән очрашу vтте. Торле ел Олкә тозv студент отрядлары штаб командирлары Петр Автаев, Владимир Егоров, Владимир Грибанов советлар чоры отрядлары тормышы белән һәм нәрсә белән истәлекле икәнен сойләп бирделәр.
Петр Автаев: «Без эшләгән вакытта да студент отрядлары актив эшчәнлек алып бара иде. Тырыш хезмәт, урнашкан урында мәдәни агарту эше алып бару, жирле халык белән дуслык-татулык урнаштыру, vзара яхшы могаләмәдә булу кебек монәсәбәтләр остенлек сорде бу студентлар отрядларында. Тагы Мордовия студентлары Краснодар, Астрахань олкәләренә помидорлар һәм бахча яшелчәләрен жыярга ярдәм итә идек»,- ди.
«Стройотрядлар дисциплинага тарта иде, мостәкыйльлеккә, жаваплылыкка ойрәтте. Анда яшvсмерләр олыландылар. Ләмберә районы Пензятка авылында эшләгәнебез хәтеремдә, - дип Россиянен атаклы тозvчесе Владимир Егоров истәлекләре белән уртаклашты. – 20-22 яшьлек повар кызларга 30 яшь егетләрне коненә оч тапкыр ашатырга кирәклеге исемдә. Бу хормәткә лаеклы хезмәт! Алар тырышлар, олгерләр, унганнар булдылар. Аларнын берсен тормыш иптәше буларак сайладым да, дип сойләде ул. Тагы АО «Газпром газораспределение Саранск» генераль директоры Мордовиядә 70нче елларда мал-туар комплекслары тозедек»,- ди.
Чираттагы штаб командиры да vзенен истәлекләре белән уртаклашты: «В стройотрядах царил сухой закон, за нарушение которого могли исключить из университета, - дип билгеләп куйды «КС БАНК» президенты Владимир Грибанов.- А в 90-е годы в нашей работе появилась интернациональная составляющая. Наши студенты ездили работать в Болгарию, а болгары приезжали в Мордовию».
Вакыт кvрсәткәнчә, стройотрядчылдар торле эшләрдә актив катнашып, тормышта vз урыннарын тиз тапканнар. Мәсәлән, штаб командирларынын кvбесе житәкчеләр, сәнәгать секторынын эш алдынгылары, бизнес  олкәсендә хыялларын тормышка

ашырганнар һәм ашыралар. Алар арасында хастаханәләрдә баш табиблар, производство житәкчеләре тәрбияләнгән. Барыбызга да билгеле булганча, Мордовия Главабыз Владимир Волков 1973-1975нче елларда «Архимеды» студен отряды командиры булган, ә 1973-1983нче елларда Олкә студент отрядлары штабын житәкләгән. Студент отрядларынын ветераннары vз бурычларын vтәгәннәр. Ул вакытта алар башкарган хезмәт халык тормышында да шактый файда китергән. Бvген дә ветераннар яшьләр очен зур vрнәк булып тора.
Мордовия Главасы Владимир Волков аларга алмашка килгән республикабыз студентларнын ин активларына, 8 сентябрь конне Студент отрядлары агымына 50 яшь тулу тантанасында, эшләренә тугры һәм Ватан патриотлары булган очен Хормәт бvләкләре тапшырды. Бvләкләнvчеләр арасында Айрат Богданов (фотода), «ОЛYМПIA» студент отряды командиры да иде.
Айрат (ул да житәкче булыр, могаен) бvләкне кабул иткәч, барлык студентлар исеменнән жавап сvзе белән чыгыш ясады. Чыгышында, ана һәм анын дусларына кемнәрдән vрнәк алырга, кемнәргә тигезләнергә бар, ди.
- Без беркайчанда олы буын кешеләре йозенә тап тошермәчәкбез, - дип вәгъдә бирде тозvче студентлар отряды командиры Айрат Богданов.

**Наилә Насырова**